| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«06» июль 2021ел №37

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының 12.03.2021 ел 27 нче номерлы карары«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «әйләнә-тирә мохитне саклау турында " 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль Балтач шәһәр җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләрдә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы 12.03.20021 ел, № 27 карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның атамасын «физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләр» сүзләрен өстәргә»;

2.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында:

1) нигезләмәнең атамасын «физик һәм юридик затлар милкендә булган җир кишәрлекләре " сүзләренә өстәргә;

2) 2.2.2, 2.4, 3.3.1 – 3.3.7, 3.5, 3.14, 3.16, 3.17,3.18 пунктларны төшереп калдырырга;

3) 2.3 пунктта «милекчеләр» сүзен төшереп калдырырга;

4) 3.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга һәм утыртуга рөхсәт гариза бирү көнен дә кертеп, 13 көн эчендә бирелә.»;

5) 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Рөхсәт бирү гариза бирүченең салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы булмаганда, Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиеш (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш).»

6) 3.11 пунктында «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен «рөхсәт ителә»сүзенә алмаштырырга.

7) 3.13 пунктта « № 2 кушымта нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 1 һәм № 2 кушымталарны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм  Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru.халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин